| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ МАЙНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МАЙНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Верх.Тат. Майна **КАРАР**

22.06.2026 № 24

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 17.11.2018 ел, № 77 карарына үзгәреш кертү хакында (үзгәрешләр белән 22.03.2019 №92; 18.11.2019 №104; 06.08.2020 №121; 02.08.2024 №69 карары)**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге Советының 17.11.2018 ел, № 77 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (үзгәрешләр белән 22.03.2019 №92; 18.11.2019 №104; 06.08.2020 №121; 02.08.2024 №69 карары) түбәндәге үзгәреш кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2,5 % карата:

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларын, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;»

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Майна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 17.11.2018 ел, №77 карарына үзгәреш кертү хакында 2026 елның 15 маендагы 22 номерлы карары (үзгәрешләр белән 22.03.2019 ел, №92; 18.11.2019 ел, №104; 06.08.2020 ел, №121; 02.08.2024 №69 карары).

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Майна авыл**
**җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Я.Д. Иванов**